КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1332

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2009 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм аларның хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2009 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 октябрь, 952 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

21 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

22 пунктның беренче абзацында «һәм компенсация түләүләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

23 пунктта:

икенче абзацта «50» саннарын «8» санына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «25 процент күләмендәге премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер» сүзенә алмаштырырга;

унынчы абзацта «35» саннарын «7» санына алмаштырырга;

уникенче абзацта «50» саннарын «10» саннарына алмаштырырга;

24 пунктта:

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «тугыз айлык тариф ставкалары» сүзләрен «1,8 айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «өч айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендәге премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин